**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Исполнительный комитет
Чубар-Абдулловского
сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района
ул. Советская, д.81, с.Чубар-Абдуллово,
423323
Тел. (8-85592) 38-7-37

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы
Чубар-Абдул авыл жирлеге
башкарма комитеты

Совет урамы, 81, Чубар-Абдул авылы,
423323
Тел. (8-85592) 38-7-37

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
01.08.2019

КАРАР
№44

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 24.03.2004 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Чубар-Абдул авыл җирлеге Уставы нигезендә

Чубар-Абдул авыд җирлеге Башкарма комитеты карар чыгара:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башлык Н. Ә. Фәтхетдинов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Башкарма кмитет карарына кунымта №1
01.08.2019 №44

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарныц үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 31 мартка кадәр үзара салым акчаларын җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, түли.

3. Аерым категория гражданнар өчен:

а) 2 төркем инвалидлар,

б) 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар,

в) күп балалы гаиләләр,

түләү күләме җирле референдум (гражданнар җыенында) карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Бер тапкыр бирелә торган түләү турында хәбәрнамә (хәбәрнамә) бланкы, җирлек сайтында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгару (халыкка җиткерү) юлы белән, гражданнарга җиткерелә: http://aznakayevo.tatarstan.ru шулай ук почта элемтәсе аша имза яисә юллама тапшыру юлы белән (әлеге Тәртипкә кушымта).

Хәбәрнамәдә (хәбәрнамәдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнардан кергән үзара салым акчалары Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Түләүләр физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясауга хокукы булган оешмалар аша, почта күчерүләрен (исәп-хисап оешмаларын) башкаруга, Чубар-Абдул авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша бирелә. https://uslugi.tatarstan.ru/

8. Түләү фактын раслап, керемле касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы "Чубар-Абдул авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге торак пукнктларында
гражданнарның үзара салым акчаларын җыю
Тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № ______________

Түләүченең Ф.И.О.
____________________________________________________________________
Адрес: ________________________________________________________
______________________________________________________нигезендә
Сезгә ________ кадәр үзара салым буенча бер тапкыр түләү түләргә кирәк.
_____________ сум
реквизитлар:_______________________________________________
алучы банкы БИК ___________________________________
Сч. № _______________________________
Сч. № ______________________________________
ИНН _______________________________________
КПП _______________________________________
КБК ______________ ОКАТО _________________
Түләүнең билгеләмәсе
____________________________________________________________________

Җитәкче________________ _____________________________________
М.П. (имза) (расшифровка)

------------------ **кисеп алу линиясе** ---------------

Хәбәрнамә (Уведомление) № ________________
бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү түләү турында
_____________________
*(муниципаль берәмлек исеме)*

________________ сум
Түләүченең Ф.И.О. ___________________________________________________
Адресы:
____________________________________________________________________
«__» ______________ 20__ г. ___________________________________
(түләүче имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өземтә (корешок)_____ авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.*